**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Кәкре Елга авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Кәкре Елга авылы № 135-70 “20” декабрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының 2014 елның 11 августындагы 100нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында 13.11.2015 № 15, 06.12.2016 №45, 23.04.2019№ 134, 19.02.2021 № 160, 22.03.2021 № 23-11, 11.10.2021 № 40-20, 31.01.2023 № 75-38, 19.09.2023№ 92-48, 01.02.2024 № 104-53, 07.05.2024 № 112-58, 28.11.2024 №130-67 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Кәкре Елга авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының 2014 елның 13.11.2015 № 15, от 06.12.2016 №45, от 23.04.2019№ 134, от 19.02.2021 № 160,от 22.03.2021 № 23-11, от 11.10.2021 № 40-20, от 31.01.2023 № 75-38, от 19.09.2023№ 92-48,от 01.02.2024 № 104-53, от 07.05.2024 № 112-58, от 28.11.2024 №130-67 карарлар редакциясендә) түбәндәге эчтәлекле 10.2 бүлек өстәп, үзгәреш кертергә:

"10.2 бүлек. Анкета тапшыру, анкетадагы белешмәләрнең үзгәрүе турында хәбәр итү һәм белешмәләрне тикшерү

1. Гражданин муниципаль хезмәткә кергәндә анкета тапшыра.

2. Муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) анкетадагы белешмәләргә мәгълүм булган үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итә.

3. Анкетаның формасы, шул исәптән аңа кертелә торган белешмәләр исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм вакыты Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

4. Анкетадагы белешмәләр яллаучы (эш бирүче) вәкиле яисә ул вәкаләт биргән зат карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетадагы белешмәләрне тикшерү гавами хакимият органнарына һәм тиешле мәгълүматка ия оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, гарызнамәләр җибәрү юлы белән муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла. Гавами хакимият органнары һәм тиешле мәгълүматка ия оешмалар әлеге сорауны алган көннән бер айдан да соңга калмыйча сорала торган мәгълүматны бирергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә" түбәндәге веб-адрес буенча http://aznakaevo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.М.Мөхәмәтҗанов